| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 октябрь 2016ел № 5553

Экология экспертизасы үткәрелергә тиешле, күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгать тыңлаулары формасындагы иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакында нигезнамәне раслау турында

«Экология экспертизасы турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ санлы Федераль законга, РФ Дәүләт экология комитетының «Россия Федерациясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү турындагы нигезнамәне раслау турында» 2000 елның 16 маендагы 372 нче Боерыгына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законга туры китереп һәм шәһәр Уставы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Экология экспертизасы үткәрелергә тиешле, күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгать тыңлаулары формасындагы иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) җәмәгать тыңлаулары формасындагы иҗтимагый фикер алышуны үткәрү буенча комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары В.А. Гавриловка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

Ә.А. Галиәкбәрова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Башкарма комитетының
2016 елның 21 октябрендәге
5553 нче карарына
1 нче кушымта

Экология экспертизасы үткәрелергә тиешле, күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгать тыңлаулары формасындагы иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакында нигезнамә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезнамә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставы нигезендә экология экспертизасы үткәрелергә тиешле, күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгать тыңлаулары формасындагы иҗтимагый фикер алышуны оештыру һәм үткәрү тәртибен (алга таба – тәртип) билгели.

2. Күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгать тыңлаулары формасындагы иҗтимагый фикер алышулар (алга таба – җәмәгать тыңлаулары) һәркемнең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә һәм аның торышы турында дөрес мәгълүматка конституцион хокукларын тормышка ашыру максатында, шулай ук закон нигезендә, уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларына кагылышлы карарлар кабул итүдә гражданнарны катнаштыру максатында үткәрелә.

3. Җәмәгать тыңлауларының инициаторы тарафыннан иҗтимагый фикер алышу формасын җәмәгать тыңлаулары формасында үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, «Экология экспертизасы турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, җәмәгать тыңлауларына дәүләт экология экспертизасы объектлары чыгарыла.

## 2. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү турында карар

4. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү турындагы карар Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.

5. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү турындагы карарда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- җәмәгать тыңлауларының темасы;
- җәмәгать тыңлауларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны.

6. Экология экспертизасы үткәрелергә тиешле, күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгать тыңлауларын җәмәгать тыңлаулары формасындагы иҗтимагый фикер алышуны үткәрү буенча комиссия (алга таба – җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия) үткәрә.

Җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия составы һәм аның эшчәнлегенең тәртибе Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан раслана.

7. Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны җәмәгать тыңлауларының инициаторы түли.

8. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия, җәмәгать тыңлауларын үткәрү датасына кадәр 30 көн алдан, җәмәгать тыңлауларын үткәрү турындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастыруны тәэмин итә.

9. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү срогы, аларны үткәрү вакыты һәм урыны турында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшәүчеләргә хәбәр ителгән вакыттан соң җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәләре турындагы бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр бер айдан артык булырга тиеш түгел.

10. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү турындагы хәбәр формасында түбәндәгеләр булырга тиеш:

- җәмәгать тыңлауларының темасы;
- җәмәгать тыңлауларын үткәрү датасы, вакыты, урыны;
- күздә тотылган эшчәнлекнең исеме, максаты һәм урнашу урыны;
- инициаторның (заказчының яки аның вәкиленең) исеме һәм адресы;
- җәмәгать тыңлауларын үткәрүнең якынча сроклары;
- җәмәгать тыңлауларын оештыруга җаваплы орган;
- күрсәтмәләр һәм тәкъдимнәрне кабул итү тәртибе һәм сроклары;
- күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек материаллары белән танышу срогы һәм урыны;
- башка мәгълүмат.

11. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) җәмәгать тыңлауларына әзерлек һәм аларны үткәрү буенча эш планы төзү;

2) җәмәгать тыңлауларында катнашучылар тарафыннан тапшырылган материалларны анализлау;

3) кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерү һәм җәмәгать тыңлауларында фикер алышуга чыгарылган конкрет мәсьәләләр исемлеген билгеләү;

4) җәмәгать тыңлауларында эксперт буларак катнашырга чакырылучы вазыйфаи затлар, белгечләр, оешмалар һәм җәмәгатьчелекнең башка вәкилләре исемлеген билгеләү һәм аларга фикер алышуга чыгарыла торган мәсьәләләр буенча үз тәкъдимнәрен кертүне сораган рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

5) чакырылган затлар составын кертеп, җәмәгать тыңлауларында катнашучы затлар исемлеген төзү;

6) доклад ясаучыларны билгеләү;

7) җәмәгать тыңлауларындагы чыгышларның тәртибен һәм эзлеклелеген билгеләү;

8) җәмәгать тыңлауларының беркетмәсен алып бару;

9) җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәләре буенча бәяләмә чыгару;

10) әлеге тәртип нигезендә башка мәсьәләләр.

## 3. Җәмәгать тыңлауларының инициаторлары

12. Җәмәгать тыңлауларының инициаторлары булып дәүләт экология экспертизасы объектлары проектларының заказчылары тора.

13. Җәмәгать тыңлауларының инициаторлары:

1) җәмәгать тыңлауларын үткәргәндә оештыру-техник һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтүне тәэмин итә;

2) әлеге тәртипнең 8 пунктында билгеләнгән мәгълүмат басылып чыккан көннән соң 30 көн эчендә, ләкин җәмәгать тыңлаулары тәмамланганчы 2 атнадан соңга калмый, танышу һәм күрсәтмәләрне тәкъдим итү өчен, дәүләт экология экспертизасы объектларының проектларын, шул исәптән җәмәгатьчелекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча материалларның беренчел вариантын тәкъдим итүне тәэмин итә.

14. Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында карар кабул итү өчен инициаторлар, дәүләт экология экспертизасы үткәрелергә тиешле хуҗалык яки башка эшчәнлек төрен күрсәтеп, экология экспертизасы үткәрелергә тиешле, күздә тотылган хуҗалык яки башка эшчәнлек турында җәмәгать тыңлаулары үткәрү турындагы үтенеч язуын үз эченә алган гаризаны Башкарма комитетка тапшыралар.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

- дәүләт экология экспертизасы объектларының проектлары турында мәгълүмат;

- җәмәгать тыңлауларын үткәрүнең якынча урыны, вакыты һәм датасы турында тәкъдимнәр.

## 4. Җәмәгать тыңлауларына әзерлек

15. Башкарма комитет, җәмәгать тыңлауларының инициаторы җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында гариза биргән көннән соң ундүрт көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында Башкарма комитет карары проектын әзерли.

## 5. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү

16. Җәмәгать тыңлаулары башланыр алдыннан җәмәгать тыңлауларында катнашучылар теркәлергә тиеш. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәүне җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия гамәлгә ашыра.

Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү җәмәгать тыңлаулары башланганчы бер сәгать алдан башлана.

17. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәгәндә, физик затлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлүен һәм шәхесен раслаучы документын күрсәтә. Теркәлгән вакытта, юридик зат вәкилләре юридик затны дәүләти теркәү турындагы

таныклыкны, вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документларны, аларның шәхесен таныклаучы документларны күрсәтә.

18. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар булып, әлеге тәртипнең 16, 17 пунктлары нигезендә җәмәгать тыңлауларында катнашучылар буларак теркәлгән 18 яшькә житкән физик затлар, юридик затлар, шулай ук ижтимагый берләшмәләр тора, шул исәптән:

- инициатор, заказчы, инвестор, проект документларын, әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау ихтималы булган, күздә тотылган эшчәнлекне нигезләүче материалларны һәм дәүләт экология экспертизасы үткәрелергә тиешле башка документларны эшләүче;

- дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары;

- күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең экологик, социаль һәм икътисадый нәтиҗәләренә карата кызыксыну белдергән җәмәгатьчелек: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш территориядә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм җәмәгать тыңлауларын үткәрү көненә хокукка сәләтле булган РФ гражданнары.

19. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү җәмәгать тыңлауларында катнашучылар исемлеген исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

20. Теркәлү вакытында зат әлеге тәртипнең 18 пунктында күздә тотылган документларны күрсәтмәгән яисә әлеге тәртип нигезендә җәмәгать тыңлауларында катнашучы булып тормаган очракта, теркәүне кире кагу рөхсәт ителә.

21. Теркәлү узмаган затлар җәмәгать тыңлауларына кертелми.

## 6. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү

22. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисе җәмәгать тыңлауларын ача, җәмәгать тыңлауларының темасын, җәмәгать тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәләләр исемлеген, җәмәгать тыңлауларындагы чыгышларның тәртибе һәм эзлеклелеге буенча Комиссия тәкъдимнәрен, җәмәгать тыңлауларында доклад ясаучыны игълан итә, җәмәгать тыңлауларының секретаре белән таныштыра.

23. Җәмәгать тыңлауларының секретаре җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен алып бара.

Җәмәгать тыңлаулары беркетмәсендә җәмәгать тыңлауларын үткәрү датасы һәм урыны, җәмәгать тыңлауларында катнашучылар саны, рәисенең, рәис урынбасарының, секретарының һәм комиссиянең башка әгъзаларының, доклад ясаучының яки җәмәгать тыңлауларында чыгыш ясаучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, аларның докладының яки чыгышының кыскача эчтәлеге, тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар, башка гамәлләр чагылдырыла.

Җәмәгать тыңлауларының беркетмәсе җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

24. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисе төп доклад ясаучыга, җәмәгать тыңлауларының чыгыш ясау хокукына ия катнашучыларына һәм чакырылган затларга, чыгыш ясау өчен, чират тәртибендә сүз бирә.

25. Һәр чыгыштан соң җәмәгать тыңлауларының теләсә кайсы катнашучысы доклад ясаучыга сорау бирергә хокуклы.

26. Чыгыш ясарга теләүчеләр саныннан чыгып, җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисе җәмәгать тыңлауларында чыгыш ясаучы теләсә кайсы катнашучының чыгыш ясау вакытын чикләргә хокуклы.

Җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисе җәмәгать тыңлауларында тәнәфес игълан итәргә хокуклы.

27. Чыгышлардан соң фикер алышуны оештыру өчен, җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисе фикер алышу үткәрелә торган мәсьәләне игълан итә һәм, үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен, җәмәгать тыңлауларының чыгыш ясау хокукына ия катнашучыларына сүз бирә.

Барлык чакырылган затлар бары тик җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисенең рөхсәте буенча гына чыгыш ясыйлар.

28. Җәмәгать тыңлауларының чыгыш ясау хокукына ия катнашучысының чыгышы тәмамланганнан яисә чыгыш ясау өчен бирелгән вакыт узганнан соң, җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисе җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга чыгыш ясаучының позициясе һәм (яки) аргументлары буенча аныклаучы сораулар бирү мөмкинлеге һәм сорауларга җавап бирү өчен өстәмә вакыт бирә. Сорауларга җавап бирү вакыты җәмәгать тыңлауларында катнашучының төп чыгышы вакытыннан артык булырга тиеш түгел.

29. Сораулар язма рәвештә дә, телдән дә бирелергә мөмкин.

Язма рәвештә бирелгән сораулар җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисенә тапшырыла һәм телдән бирелгән сорауларга җавап бирелгәннән соң игълан ителә.

30. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар, җәмәгать тыңлаулары беркетмәсенә кертү өчен үз тәкъдимнәрен һәм күрсәтмәләрен җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисенә җиткерергә хокуклы.

31. Җәмәгать тыңлауларының чыгыш ясау хокукына ия катнашучысы үз тәкъдимнәрен кире алырга һәм (яки) җәмәгать тыңлауларының башка катнашучыларының тәкъдимнәренә кушылу хокукына ия. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның карала торган мәсьәлә буенча позицияләрен үзгәртү турындагы карарлары җәмәгать тыңлаулары беркетмәсендә чагылдырыла.

32. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның һәр мәсьәлә буенча чыгышлары тәмамланганнан соң, җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисе аларга фикер алышу йомгаклары буенча үз позициясен үзгәртү ихтималы турында сорау белән мөрәҗәгать итә.

33. Җәмәгать тыңлаулары темасының барлык мәсьәләләре буенча да фикер алышулар тәмамланганнан соң җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча комиссия рәисе, җәмәгать тыңлаулары темасының барлык мәсьәләләрен

караганнан соң, йомгаклау документында калган тәкъдимнәрне ачыклау өчен секретарьга сүз бирә.

34. Җәмәгать тыңлауларының барлык теләгән катнашучылары тикшерелә торган проект буенча үз фикерләрен белдергәннән соң, җәмәгать тыңлаулары тәмамланган дип санала.

## 7. Җәмәгать тыңлауларының нәтиҗәләре

35. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү йомгаклары буенча беркетмә төзелә.

36. Җәмәгать тыңлаулары беркетмәсендә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- кергән тәкъдимнәрнең гомуми саны;
- комиссия тарафыннан кире кагылган мәсьәләләр саны;
- җәмәгать тыңлауларына чыгарылган, ләкин кабул ителмәгән мәсьәләләр;
- җәмәгать тыңлауларында кабул ителгән мәсьәләләр.

Җәмәгать тыңлауларын үткәрү беркетмәсе күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча материалларның соңгы вариантына кушымталарның берсе буларак теркәлә.

37. Комиссия рәисе җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен раслаган вакыттан соң өч көн срокта, Башкарма комитет җәмәгать тыңлаулары беркетмәсен җәмәгать тыңлауларын үткәрү инициаторына җибәрә.

38. Күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне тормышка ашыру турында карар кабул ителгәнгә кадәрге чорда гражданнардан һәм иҗтимагый оешмалардан язмача күрсәтмәләрне һәм тәкъдимнәрне кабул итү, әлеге тәкъдимнәрне әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча материаллар кушымтасында документлаштыру, җәмәгать тыңлаулары тәмамланганнан соң 30 көн эчендә җәмәгать тыңлауларының инициаторы (заказчы) тарафыннан тәэмин ителә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2016 елның 21 октябрендәге
5553 нче карарына
2 нче кушымта

Җәмәгать тыңлаулары формасындагы
иҗтимагый фикер алышуны үткәрү буенча
комиссия составы

| | |
|---|---|
| Гаврилов В.А. | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Кыямов Р. Ә. | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| Рева Е.Н. | комиссия секретаре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенең баш белгече |
| комиссия әгъзалары: | |
| Әхмәтова Г.К. | Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе |
| Галимов И. Н. | Башкарма комитетның Үзәк районы Хакимияте Башлыгы |
| Гарипов Н.Г. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе башлыгы (килешенү буенча) |
| Кислов А. И. | Башкарма комитетның Комсомол районы Хакимияте Башлыгы |
| Насыйбуллин А.Ә. | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» МКУ башлыгы |
| Усманова Р. М. | Башкарма комитетның Автозавод районы Хакимияте Башлыгы |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова